| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ<br>«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»<br>ЧИСТОПОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ** | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>**ЧИСТАЙ<br>ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ** |
|---|---|

***Решение*** ***Карар***

**2019 елның 7 нче октябре** **Чистай шәһәре** **№39/3**

Чистай шәһәр Советының
2016 елның 10 ноябрендәге
“Җир салымын түләү ставкасын,
тәртибен һәм срокларын билгеләүне
гамәлгә кертү турында”гы 9/1 номерлы
Карарга үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**Карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 10.11.2016 елгы “Җир салымын түләү ставкасын, тәртибен һәм срокларын билгеләүне гамәлгә кертү турында”гы 9/1нче карарына (Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 07.08.2017 елгы 16/3нче, 27.06. 2018 елгы 26/3 нче, 23.11.2018 елгы 29/2 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“ - шәхси хуҗалык алып бару, бакчачылык, яки яшелчәчелек алып бару өчен алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук “Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,2 процент күләмендә.”.

2. Әлеге карарны масса-күләм мәгълүмат чараларында,“Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүматлар порталында” (pravo.tatarstan.ru) бастырырга, шулай ук Чистай муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтында www.chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарныңүтәлүенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы
вазыйфаларын башкаручы М.И.Ксенофонтов